Арбор төп мәктәбе

**Тема: “Юл йөрү кагыйдәләре патшалыгы”на сәяхәт.**

(мәктәпнең яшь юл инспекторлары белән балалар бакчасында үткәрелгән чара)

Төзеде: Мифтахова Р.Б.

2021

Максат:

1. Яшь юл инспекторларының юл билгеләре һәм юл йөрү кагыйдәләре турындагы белемнәрен камилләштерү.

2. Нәниләр белән үзләренең юл билгеләре һәм юл йөрү кагыйдәләре турындагы белемнәрен өйрәтү.

3. Төрле дидактик уеннар, ситуатив мәсьәләләр аша балаларда игътибарлылык, тәрбия ләү, уйлау сәләтләрен үстерү.

4. Балаларда дуслык, бер-береңә ярдәмчел булу сыйфатларын тәрбияләү.

Материал: транспорт төрләре, уенчык машиналар, ситуатив мәсьәләне чагыл-дырган рәсемнәр, юл билгеләре, магнитофон язмасында машиналар тавышы, зур юл макеты, "серле" җәймә

Чара барышы:

Алып баручы – Яшь инспектор:

- Хәерле көн, безнең нәни дусларыбыз! Бүген без кабат сезнең белән очрашуга килдек. Безне онытмадыгызмы? Без кемнәр?
- Рәхмәт, онытмагансыз икән. Әйе, без - мәктәпнең яшь юл инспекторлары. Үзебез дә тырышып юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнәбез, үзебез белгәне сезгә дә өйрәтәсебез килә. Бүген без сезне “Юл йөрү кагыйдәләре патшалыгы”на сәяхәткә чакырабыз. Киттекме?! Тик ул патшалык бик ерак. Ә сезнең ул патшалыкка нинди төр транспорт белән барасыгыз килә?

Балалар.

-Минем паровозик белән барасым килә

-Ә мин машинада барыр идем

-Минем кораблик белән барасым килә.

-Ә мин такси чакыртам да барам

-Минем вертолетта очып барасым килә

Ә мин КАМАЗ белән барыр идем.

Алып баручы – Яшь инспектор:

Юк, нәни дуслар, сезнең бу төр транспортларга утырып йөргәнегез бар инде. Бүген без сезнең белән әкиятләрдә генә була торган серле җәймәгә утырып барачакбыз. Телисезме?!

- Патшалыкның юллары бик катлаулы, буталчык. Сезгә бик күп сынаулар үтәргә туры киләчәк. Кагыйдәләрне төгәл үтәсәгез, патшалыкның кадерле кунаклары булырсыз.

- Сез зур сынаулар үтәргә әзерме?

-Авырлыклардан курыкмассызмы? Киттек алайса...

Ягез әле, килегез әле бирегә, уңайлы итеп утырыгыз, кулга кул тотыныгыз. Күзләрегезне йомыгыз. (Балалар бер җәймәгә утыралар һәм күзләрен йомалар, серле музыка уйный. Күзләрен ачуга светофор килеп чыга).

А.б. Балалар, Кем икән бу безнең каршыда?

Балалар. Светофор,бу!

А.б. .Дөрес, балалар, бу -светофор. Әйдәгез сүзне светофорның үзенә бирик.

Светофор.

Сак йөрегез! Күзләрегез
Булсын гел юлда гына .
Чыгыгыз урам аша,
Тиеш урыннан гына.

(Светофор балаларга уен уйната).

А.б. Рәхмәт, светофор!Ә хәзер без сезгә , светофор белән бергә уен тәкъдим итәбез.

-Яле, светофор, миңа үз төсләреңне бир эле?

Светофор уены. Минем кулда 3 төсле түгәрәк, алар – светофор төсләрендә, -----Кызыл түгәрәк күтәрелсә – бер – берегезгә бармак янагыз. --- Сары түгәрәк күрсәгез – бер урында атлап торырсыз. --- Яшел түгәрәкне күтәрсәм – хәрәкәт итәрсез, яки атлап йөрерсез. Килештекме? Бер, ике, өч – уен башланды!

-Рәхмәт, балалар! Сез бик ихтибарлы булдыгыз.Ә хәзер юлыбызны дәвам итәбез.

Хәерле юл, дусларым,
Исән – имин йөрегез.
Юлда тәртипле булуның ,
Файдасы күп, белегез.

А.б. . Әйдәгез, балалар, хәзер юлыбызны дәвам итәбез, "Шигърият аланы”на килеп җитәбез.

(Балалар тезелеп баса)

Һәлакәтләр булмасын дип
Телидер һәрбер йөрәк
Шуңа күрә дә йөргәндә
Бик сак булырга кирәк!

Юл кагыйдәсен белмәүче
Урам – юлда йөрмәсен
Бик йөрисе килә икән
Кагыйдәсен өйрәнсен.

Юкка гына әйтмәгәннәр:
Ашыккан – ашка пешкән.
Сабыр иткән – барып җиткән,
Чыгармагыз сез истән.

Юлны аркылы чыкканчы
Карап ал сулга – уңга.
Якында машина күрсәң,
Ашыкма, чыкма юлга

Кайда гына йөрсәгез дә
Игътибарлы булыгыз.
Кагыйдәләрне үтәгез.
Имин булсын юлыгыз.

А.б. Булдырдыгыз , рәхмәт, балалар, ә хәзер “Уен аланы”на барып, бераз уйнап алыйк.

**Уеннар:**

1. Гаражга машина  илтү (“йөртеп” машинаны кольцо эченә кем тизрәк илтә)
2. ЮИД чы эстафетасы (бара, жилет кия, кепка, кулын күтәрә, сала, кире килә)
3. Юл билгесенең  рәсемен  ясыйлар.
4. Машинаны я тупны берсе илтә, берсе алып килә.
5. Юл билгеләрен тану.
6.”Машинаны дөрес җый!” дип атала алдагы уеныбыз. -Безгә дөрес һәм тиз итеп,  пазллардан машинаны җыярга кирәк.

**1.а.б.4.” Ярый, ярамый” уены**

Хәзер “ Ярый, ярамый “ дигән уен уйнап алабыз. Пассажирларга үтәргә ярый торган эш булса-атлыйбыз, ярамый торган эш булса - чүгәлибез.

**1 командага**.

-юлны аркылы чыкканда башта сулга карарга ( ярый )

-юлны теләсә каян чыгарга ( ярамый )

-тукталышта этешә - төртешә уйнарга ( ярамый )

-троллейбуста буш урын булса, утырырга (ярый )

-трамвайда өлкәннәргә урын бирергә ( ярый )

-автобусның ишегенә терәлеп барырга ( ярамый)

**2.а.б.2 командага**

-Светофорда яшел ут янганда юл аркылы чыгарга ( ярый)

-Юлны теләсә кайдан чыгарга (ярамый)

-Велосипед белән теләгән урында йөрергә (ярамый)

-Автобус ишегенә терәлеп барырга (ярамый)

-Автобус яки машина артына тотынып барырга (ярамый)

-Җәяүлегә машина хәрәкәтенә каршы барырга (ярый)

**1 нче командага сораулар.**

1.Автобус көтү урыны. (тукталыш)
2.Җәяү йөрүче кем дип атала? (җәяүле)
3.Светофорның ничә төсе бар? (3)
4.Машина юлы аша ничек чыгарга? ( җәяәүлеләр чыгу (пешеходный переход) юлы)
5.Велосипедта ничек йөрергә ярамый? (кулны җибәреп)
6.Җәяүлеләр өчен яшел ут янса, машиналар өчен тинди төс янар?( кызыл)
7.Җәяүле юлы.( тротуар)
8.Автобусны ничек әйләнеп узарга? (әйләнеп узарга ярамый, киткәнен көтеп торырга, һәм куркынычсыз урыннан чыгарга)

9.Нинди транспорт төрләре бар? (Су, һава, коры җир транспорты)

10.ЮХИДИ ничек була? (Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе)

**2.а.б. 2 командага сораулар**

1. Ничә яшьтән юлда велосипедта йөрергә ярый? ( 14)

2.Автобус көтү урыны. (тукталыш)

3.Транспортта баручы ничек атала? (пассажир)

4.Зебра ничә төсле? (2)

5. Трамвайны ничек әйләнеп узарга? (әйләнеп узарга ярамый, киткәнен көтеп торып, куркынычсыз урыннан чыгарга кирәк)

6.Трамвай кайдан йөри? ( рельстан)

7.Светофор ни өчен кирәк? ( юлдагы хәрәкәтне көйләр өчен)

8.Транспорт белән идарә итүче (водитель, транспорт йөртүче)

9.Велосипедта кемнәрне утыртып йөрергә ярый (кеше утыртып йөрергә ярамый)

10. Светофорда кызыл сигнал кайда урнашкан? (иң өстә)

**1.а.б**.Юл йөрү билгеләре ничә төргә бүленде?( 8)

**Ситуация:**Сез велосипедта йөргәндә үзегезнең иң якын дустыгызны күрдегез.Ләкин ул юлның икенче ягында сезне чакыра .Сез нишлисез?

Юл сүзендә ничә аваз бар?( 3)

**Ситуация**: Машина юлында велосипед белән йөрергә ярыймы?Ә ни өчен?

Зебра ничә төсле?(2)

**Ситуация:**Сезгә юл арткылы чыгарга кирәк.Зебра тамгасы ераграк.Бу очракта нишлисез?

Юл транспорт халәкәтенең ничә сәбәбен белдек.( 5)

**Йомгаклау.**

**1.а.б.Укытучы.** Менә безнең уеныбыз тәмамланды. Балалар үзләренең юл йөрү кагыйдәләрен нинди дәрәҗәдә белүләрен күрсәттелә.Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнүне киләчәктә дә дәвам итәрбез.

Кадерле балалар, юл билгеләре безгә бик күп нәрсә турында сөйли. Кирәк чакта боералар, кирәк чакта кисәтәләр. Аларның һәрберсе һәлакәтләр булмасын өчен куелган. Шуңа күрә **юлда йөрү кагыйдәсен** б**елергә тиеш һәркем!** Шул вакытта гына безнең сәламәтлегебезгә куркыныч янамас.

Кайтканда без шулай ук үзебезнең тылсымлы келәмебезгә утырып кайтырбыз. Утырыштык, киттек.








03